| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>СТАРОДРОЖЖАНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСКЕ ЧҮПРӘЛЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27 января 2021 г. ИСКЕ ЧҮПРӘЛЕ № 20

Агач һәм куаклар кисүгә, кронлауга яки
утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль
хезмәт күрсәтүнең административ
регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 ел 26 августында 100 номерлы карары белән расланган ( №102 12.09.2019 ел редакциясендә) “Агач һәм куаклар кисүгә, кронлауга яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына” түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**2.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле пунктча** өстәргә:

«2) үтәү вакыты Россия Федерациясе законнары нигезендә (авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш) килгән очракта, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә”.

**2.8 пунктка** түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“5)Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу”

**3.4.1 пунктка** түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында белешмәләр.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Иске Чүпрәле авыл җирлеге
Башкарма комитет
Җитәкчесе: В.М.Салахутдинова